ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМБАКТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАРЫ

24.08.2020 ел N 18

## Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергн мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау буенча бердәм тәртип билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты:

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ :

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга .

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең рәсми сайтында: / www. spasskiy.tatarstan.ru-хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru( законда билгеләнгән срокта бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Ямбакты авыл җирлеге башлыгы : И.Ә. Галәветдинов.

Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге
Башкарма комитет
карары буенча кушымта
"24" август, 2020 ел, № 18

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә Анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә Анализ тиешле чорга кергән барлык мөрәҗәгатьләр, шул исәптән язма рәвештә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә Анализ ел саен башкарыла.

5. Хисап чорыннан соң килгән айның 10 числосына кадәр гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхсән күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш (булганда).

7. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә Анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Башкарма комитет сәркатибе ел саен аналитик белешмәне авыл җирлегенең рәсми сайтында "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.